КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 25 июль г.Казань № 594

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 6 май, 574 нче карары белән расланган Хуҗалык-көнкүреш су белән тәэмин итү системаларын (су белән тәэмин итүнең бүлү челтәрләреннән тыш) һәм каты коммуналь калдыкларны җыю һәм чыгару мәйданчыкларын төзү, капиталь ремонтлау һәм реконструкцияләү эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен финанс белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан бакчачылык һәм яшелчәчелек коммерциягә карамаган ширкәтләренә субсидия бирү тәртибенә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хуҗалык-көнкүреш су белән тәэмин итү системаларын (су белән тәэмин итүнең бүлү челтәрләреннән тыш) һәм каты коммуналь калдыкларны җыю һәм чыгару мәйданчыкларын төзү, капиталь ремонтлау һәм реконструкцияләү эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен финанс белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан бакчачылык һәм яшелчәчелек коммерциягә карамаган ширкәтләренә субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2023 ел, 6 май, 574 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 27 февраль, 99 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Хуҗалык-көнкүреш су белән тәэмин итү системаларын (су белән тәэмин итүнең бүлү челтәрләреннән тыш) һәм каты коммуналь калдыкларны җыю һәм чыгару мәйданчыкларын төзү, капиталь ремонтлау һәм реконструкцияләү эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарның бер

өлешен финанс белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан бакчачылык һәм яшелчәчелек коммерциягә карамаган ширкәтләренә субсидия бирү тәртибенә, 1.1 пунктның беренче абзацында «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Субсидияләр бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне, юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук физик затларга - товар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә, һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының үз көчләрен югалтуын тану турында гомуми таләпләр хакында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары белән» сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин